РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
НИЖНЕКАМСКИЙ
ГОРОДСКОЙ СОВЕТ

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА ШӘҺӘР
СОВЕТЫ

Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

Тел./факс: (8555) 42-42-66. E-mail: Gorsovet.Nk@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2024 елның 8 октябре № 32

Түбән Кама шәһәре урамнарына исемнәр бирү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлеге Уставының 6 статьясы, Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты каршындагы топонимика комиссиясенең 2024 елның 13 сентябрендәге карарын исәпкә алып, Түбән Кама шәһәр Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Түбән Кама шәһәренең 46 нчы микрорайонында төзелә торган яңа урамнарга исемнәр бирергә:

-46 нчы микрорайонның төньяк-көнбатыш юнәлешендә Кояшлы урамының 19 нчы йорты тирәсендә башланып, урман массивына кадәр «Кедровая урамы» – «Кедрлы урамы»;

-Кояшлы урамындагы 39 нчы йорт янында 46 нчы микрорайонның төньяк-көнчыгыш юнәлешендә урман массивына кадәр «Наратлы урамы» - «Наратлы урамы».

2. Түбән Кама шәһәре Башкарма комитетына аталган урамнарның торак һәм җәмәгать объектларында адреслы атрибутика урнаштыруны тәэмин итүне йөкләргә.

3. Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының мәгълүмат-аналитика бүлеге башлыгына Түбән Кама шәһәренең 46 нчы микрорайонында төзелә торган яңа урамнарның исемнәрен массакүләм мәгълүмат чараларында киң яктыртуны тәэмин итүне йөкләргә.

4. Әлеге карар Түбән Кама шәһәре Уставында каралган тәртиптә рәсми басылып чыгу вакытыннан үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Түбән Кама шәһәр Советының шәһәр инфраструктурасын үстерү буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Түбән Кама шәһәре Мэры — Р.Х. Муллин

МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ ГОРОД НИЖНЕКАМСК РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТҮБӘН КАМА ШӘҺӘРЕ МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ПРЕДСТАВИТЕЛЬНЫЙ ОРГАН
ВӘКИЛЛЕКЛЕ ОРГАН